3.2. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$- дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$- дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикалар дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикалар дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 2 нче таблицасында бирелгән.

3.3. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләү күләмен билгеләү алар бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләге булган хезмәткәрләргә алар булган өчен түләү хезмәткәр сайлавы буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

3.4. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә, хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәүне исәпкә алып, һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

биредә:

$B_s$- профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$- профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме, 11 нче таблицада бирелгән.

11 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 1,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | 15 елдан артык | 2,5 |
| Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | 15 елдан артык | 4,0 |

3.5. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән, стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, яки стажны раслый торган кирәкле документны тапшырган көннән башкарыла.

4. Спорт резервын әзерләү оешмалары медицина хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү күләме һәм тәртибе.

4.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тотучы белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

биредә:
$B_{kk}$ - квалификация категориясе өчен түләү;
$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
$D_{kk}$- квалификация категориясенә өстәмә күләме, 12 нче таблицада бирелгән. Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

12 нче таблица

**КВАЛИФИКАЦИЯ КАТЕГОРИЯСЕ ӨЧЕН ӨСТӘМӘЛӘР КҮЛӘМЕ**

| Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процентларда |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 3,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| Югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 6,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| Югары квалификация категориясе | 20,0 |

4.2. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр аерым учреждениеләрдә медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

биредә:

$B_{sd}$- эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sd}$- эшчәнлек үзенчәлеге өчен 16,2 процентка тигез итеп алынган өстәмә күләме.

4.3. Әлеге оешмада, бүлекчәдә һәм вазыйфада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеге, сайлап куелган профсоюз органы яки хезмәткәр мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле башка орган белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

4.4. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$- дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладым;

$D_{pz}$- дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикалар дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикалар дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 3 нче таблицасында бирелгән.

4.5. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләү күләмен билгеләү дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләге булган хезмәткәрләргә алар булган өчен түләү хезмәткәр сайлавы буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

4.6. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_{sr},$$

биредә:
$B_s$- профиль буенча эш стажы өчен түләү;
$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
$D_{sr}$- профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме, 13 нче таблицада бирелгән.

13 нче таблица

**ПРОФИЛЬ БУЕНЧА ЭШ СТАЖЫ ӨЧЕН ӨСТӘМӘЛӘР КҮЛӘМЕ**

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

4.7. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән, стажны раслаучы документлар оешмада булса, яки стажны раслый торган кирәкле документны тапшырган көннән башкарыла.

4.8. Хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр урта медицина һәм фармацевтика персоналы, табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

биредә:
$B_{sr}$- хезмәт киеренклеге өчен түләүләр;
$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладны;
$D_{sr}$- хезмәт киеренклеге өчен түләүләрт, 14 нче таблицада бирелгән.

14 нче таблица

**ХЕЗМӘТ КИЕРЕНКЕЛЕГЕ ӨЧЕН ӨСТӘМӘЛӘР КҮЛӘМЕ**

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмәләр диапазоны, процентларда |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | икенче | 1,5 |
| | өченче | 3,0 |
| | дүртенче | 4,5 |
| | бишенче | 10,0 |

| | | |
|---|---|---|
| Табиблар һәм провизорлар | беренче-икенче | 3,0 |

5. Спорт резервын әзерләү оешмалары физик культура хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү күләме һәм тәртибе.

5.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр икенче һәм өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләренә квалификация категориясе гамәлдә булу срогы чикләрендә гамәлдәге квалификация категориясе булганда бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

биредә:

$B_{kk}$ - квалификация категориясе өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$- квалификация категориясенә өстәмә күләме, 15 нче таблицада бирелгән.

15 нче таблица

**ФИЗИК КУЛЬТУРА ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ КВАЛИФИКАЦИЯ КАТЕГОРИЯСЕ ӨЧЕН ӨСТӘМӘЛӘР КҮЛӘМЕ**

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 5,0 (11,0 <*>) |
| | югары квалификация категориясе | 6,0 (13,0 <*>) |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 6,0 (11,0 <*>) |
| | югары квалификация категориясе | 8,5 (13,0 <*>) |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 7,5 (12,0 <*>) |
| | югары квалификация категориясе | 10,0 (15,5 <*>) |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 8,5 |
| | югары квалификация категориясе | 12,5 |
| <*> Физкультура спорт оешмалары тренеры, инструктор-методисты (шул исәптән өлкән) | | |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән башкарыла.

5.2. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр беренче, икенче һәм өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

вазыйфаи оклад буенча тарификацияләнүче хезмәткәрләр өчен:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd} \times \frac{H_{f_{sd}}}{H_n},$$

оклад (хезмәт хакы) буенча тарификацияләнүче хезмәткәрләр өчен:

$$B_{sd} = O_b \times D_{sd} \times \sum_{i=1}^{m} N_i,$$

биредә:

$B_{sd}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләү;

$D_{sd}$ - олимпия резервының махсуслаштырылган оешмаларында (бүлекчәләрендә) эшчәнлек үзенчәлеге өчен 7 процентка тигез итеп алынган өстәмә күләме;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$O_b$ - хезмәткәрләрнең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$H_{f_{sd}}$ - спорт резервын әзерләү оешмалары физик культура хезмәткәрләренең билгеле бер категория кулланучылар белән эшләү сәгатьләренең факттагы саны;

$H_n$ - спорт резервын әзерләү оешмалары педагогик хезмәткәрләре хезмәт хакының әлеге Нигезләмәнең IV бүлегендә билгеләнгән база ставкасы өчен сәгать нормасы;

$N_i$ - спорт резервын әзерләү оешмаларында спорт төрләре буенча спорт әзерлеге этапларында бер шөгыльләнүче өчен тренер-укытучылар (шул исәптән өлкән) хезмәтенә түләү нормативлары;

m - эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр билгеләү каралган кулланучылар саны.

5.3. Әлеге оешмада, бүлекчәдә һәм вазыйфада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге, сайлап куелган профсоюз органы яки хезмәткәр мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле башка орган белән килештереп, һәр оешма тарафыннан раслана.

5.4. Ярышларда алган урын нигезендә югары эш нәтиҗәләре өчен түләүләр спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында уңышлы чыгыш ясаганнары һәм ирешкән нәтиҗәләре өчен бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{vrr} = O_d \times D_{vrr},$$

биредә:

$B_{vrr}$- югары эш нәтиҗәләре өчен түләүләр;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{vrr}$ - югары эш нәтиҗәләре өчен өстәмә күләме, 16 нчы таблицада бирелгән.

5.5. Ярышларда алган урын нигезендә югары эш нәтиҗәләре өчен түләүләр ярышлар беркетмәсеннән өземтә нигезендә бер календарь ел дәвамында спортчы күрсәткән нәтиҗәдә мизгеленнән билгеләнә.

5.6. Ярышларда алган урын нигезендә югары эш нәтиҗәләре өчен түләү срогы бер календарь елга билгеләнә.

5.7. Югары эш нәтиҗәләре өчен ярышларда алынган урын нигезендә өстәмә күләме һәр дәрәҗәдәге ярышларда бер яхшы нәтиҗә өчен (спортчының сигез ярышыннан да артык түгел) спортчы, спортчы-инструктор тарафыннан программа рәвешендә күрсәтелгән шәхси зачетта, күп төр ярышта күрсәтелгән бер яхшы нәтиҗә өчен яки, әгәр медаль комплектлары уйнатыла икән, команда ярышларында нәтиҗә өчен процентлар суммасыннан формалаша.

16 нчы таблица

## ЮГАРЫ ЭШ НӘТИҖӘЛӘРЕ ӨЧЕН ӨСТӘМӘ КҮЛӘМЕ

(процентларда)

| Ярышларның дәрәҗәсе | Алынган урын | Өстәмә күләме | |
|---|---|---|---|
| | | олимпия спорт төрләре, олимпия дисциплиналары | олимпия булмаган спорт төрләре, олимпия булмаган дисциплина |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Олимпия уеннары | 1 | 500,0 | - |
| | 2 | 375,0 | - |
| | 3 | 250,0 | - |
| | 4 | 200,0 | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 5 | 187,5 | - |
| | 6 | 125,0 | - |
| | катнашу | 62,5 | - |
| Дөнья чемпионаты | 1 | 150,0 | 105,0 |
| | 2 | 140,0 | 100,0 |
| | 3 | 130,0 | 95,0 |
| | 4 | 120,0 | 90,0 |
| | 5 | 110,0 | 85,0 |
| | 6 | 100,0 | 70,0 |
| Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 | 140,0 | 100,0 |
| | 2 | 130,0 | 90,0 |
| | 3 | 120,0 | 85,0 |
| | 4 | 110,0 | 75,0 |
| | 5 | 100,0 | 70,0 |
| | 6 | 90,0 | 65,0 |
| Европа кубогы, дөнья беренчелеге | 1 | 120,0 | 85,0 |
| | 2 | 110,0 | 75,0 |
| | 3 | 100,0 | 70,0 |
| | 4 | 90,0 | 65,0 |
| Бөтендөнья универсиадасы | 1 | 120,0 | 85,0 |
| | 2 | 110,0 | 75,0 |
| | 3 | 100,0 | 70,0 |
| | 4 | 90,0 | 65,0 |
| Россия чемпионаты, Европа беренчелеге | 1 | 100,0 | 70,0 |
| | 2 | 90,0 | 65,0 |
| | 3 | 80,0 | 55,0 |
| | 4 | 70,0 | 50,0 |
| Россия кубогы, Россия беренчелеге | 1 | 80,0 | 55,0 |
| | 2 | 70,0 | 45,0 |
| | 3 | 60,0 | 40,0 |
| | 4 | 50,0 | 35,0 |
| Бөтенроссия универсиадасы | 1 | 35,0 | 17,5 |
| | 2 | 30,0 | 15,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 3 | 25,0 | 12,5 |
| | 4 | 20,0 | 10,0 |

5.8. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен түләүләр беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеменең беренче квалификация дәрәҗәсендәге хезмәткәрләренә һәм икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре буенча хезмәткәрләргә (спортсмен-инструкторлардан, спортчылардан тыш) рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында спортчыларның уңышлы чыгышлары һәм ирешкән нәтиҗәләре өчен, хезмәткәр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларының үтәлешен исәпкә алып бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{vytp} = O_d \times D_{vytp},$$

биредә:

$B_{vytp}$ - югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен түләүләр;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{vytp}$ - югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен өстәмә күләме, 17 нче таблицада бирелгән.

5.9. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен түләүләр ярышлар беркетмәсеннән өземтә нигезендә бер календарь ел дәвамында спортчы күрсәткән нәтиҗә мизгеленнән билгеләнә.

5.10. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен түләү срогы бер календарь елга билгеләнә.

5.11. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен өстәмә күләме һәр дәрәҗәдәге ярышларда (спортчының сигез ярышыннан да артык түгел) спортчы тарафыннан программа рәвешендә күрсәтелгән шәхси зачетта, күп төр ярышта күрсәтелгән бер яхшы нәтиҗә өчен яки, әгәр медаль комплектлары уйнатыла икән, команда ярышларында нәтиҗә өчен процентлар суммасыннан формалаша.

17 нче таблица

**ЮГАРЫ СЫЙФАТЛЫ УКЫТУ-ТРЕНИРОВКА ПРОЦЕССЫН ТӘЭМИН ИТКӘН ӨЧЕН ПЕДАГОГИК ХЕЗМӘТКӘРЛӘР ВАЗЫЙФАЛАРЫ ӨЧЕН ӨСТӘМӘ КҮЛӘМЕ**

(процентларда)

| Квалификация дәрәҗәсе | Ярышларның дәрәҗәсе | Алынган урын | Өстәмә күләме | |
|---|---|---|---|---|
| | | | олимпия спорт төрләре, олимпия дисциплиналары | олимпия булмаган спорт төрләре, олимпия булмаган дисциплина |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең вазыйфалары | | | | |
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 2,5 | |
| | Дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 2,5 | 1,5 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 1,5 | 1,0 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 1,5 | 1,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 1,5 | 1,0 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 1,5 | 1,0 |
| | Дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 1,5 | 1,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 1,5 | 1,0 |
| | Яшьләр, укучылар спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 1,0 | 1,0 |
| Икенче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 3,0 | |
| | Дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 3,0 | 2,5 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 2,5 | 2,0 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 2,5 | 2,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 2,0 | 1,5 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 2,0 | 1,5 |
| | Дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 2,5 | 2,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 1,5 | 1,5 |
| | Яшьләр, укучылар спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 3 | 3 |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең вазыйфалары | | | | |
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 3,5 | |
| | Дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 3,5 | 3,0 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 3,0 | 2,5 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 3,0 | 2,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 2,5 | 1,5 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 2,5 | 1,5 |
| | Дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 2,5 | 2,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 2,5 | 2,0 |
| | Яшьләр, укучылар спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 2,0 | 2,0 |
| Икенче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 4,0 | |
| | Дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 4,0 | 3,5 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 3,5 | 3,0 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 3,5 | 3,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 3,0 | 2,5 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 3,0 | 2,5 |
| | Дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 3,5 | 3,5 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 2,5 | 2,5 |
| | Яшьләр, укучылар спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 2,0 | 2,0 |
| Өченче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 5,0 | |
| | Дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 5,0 | 4,0 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 4,0 | 3,5 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 4,0 | 3,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 3,5 | 3,0 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 3,5 | 3,0 |
| | Дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 3,5 | 3,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 3,0 | 3,0 |
| | Яшьләр, укучылар спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 2,5 | 2,5 |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең вазыйфалары | | | | |
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 6,0 | |
| | Дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 6,0 | 5,0 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 5,0 | 4,5 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 5,0 | 4,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 4,0 | 4,0 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 4,0 | 4,0 |
| | Дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 4,5 | 4,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 4,0 | 4,0 |
| | Яшьләр, укучылар спартакиадасы, спорт мәктәпләре | 1 - 3 | 3,5 | 3,5 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | арасында бөтенроссия ярышлары финалы | | | |
| Икенче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 7,5 | |
| | Дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 7,5 | 6,0 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 6,0 | 4,0 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 6,0 | 5,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 5,0 | 4,5 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 5,0 | 4,5 |
| | Дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 5,5 | 5,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 4,5 | 4,5 |
| | Яшьләр, укучылар спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 4,0 | 4,0 |
| Дүртенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең вазыйфалары | | | | |
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 12,5 | |
| | Дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 12,5 | 7,5 |
| | Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 7,5 | 6,0 |
| | Европа кубогы | 1 - 4 | 7,5 | 6,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 6,0 | 5,0 |
| | Россия кубогы | 1 - 4 | 6,0 | 5,0 |
| | Дөнья һәм Европа беренчелеге | 1 - 6 | 7,0 | 7,0 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 6,0 | 6,0 |
| | Яшьләр, укучылар спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 5,0 | 5,0 |

5.12. Спорт исемнәре, спорт разрядлары өчен түләүләр спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга тиешле спорт исемнәрен һәм спорт разрядларын бирү өчен кирәк булган нормаларны һәм таләпләрне үтәгән өчен бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{szsr} = O_d \times D_{szsr},$$

биредә:

$B_{szsr}$ - спорт исемнәре, спорт разрядлары өчен түләүләр;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{szsr}$ - спорт исемнәре, спорт разрядлары өчен өстәмә күләме, 18 нче таблицада бирелгән.

5.13. Спорт исемнәре, спорт разрядлары өчен түләүләр исем яки разряд бирү турында боерык яки карар датасыннан билгеләнә.

18 нче таблица

## СПОРТ ИСЕМНӘРЕ, СПОРТ РАЗРЯДЛАРЫ ӨЧЕН ӨСТӘМӘ КҮЛӘМЕ

| Тәр-тип N | Спорт исеме (спорт разряды) атамасы | Өстәмә күләме, процентларда |
|---|---|---|
| 1. | Россиянең халыкара класслы спорт мастеры | 27,0 |
| 2. | Россиянең спорт мастеры | 20,0 |
| 3. | Россия гроссмейстеры | 20,0 |
| 4. | Спорт мастерлыгына кандидат | 9,0 |

5.14. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр физик культура хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикалар дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең дәүләт бүләкләре, спорт исемнәре, Совет Социалистик Республикалары Союзының дәүләт бүләкләре, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Физик культура хезмәткәрләренә түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре, спорт исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 4 нче таблицасында бирелгән.

5.15. Дәүләт бүләкләре, спорт исемнәре булган өчен түләүләр күләмен билгеләү дәүләт бүләге, спорт исеме бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләге, ике һәм аннан күбрәк спорт исеме булган хезмәткәрләргә алар өчен түләү хезмәткәрнең теләге буенча бер нигез буенча билгеләнә.

5.16. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

биредә:

$B_s$ - профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$- профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме, 19 нчы таблицада биерелгән.

19 нчы таблица

**ПРОФИЛЬ БУЕНЧА ЭШ СТАЖЫ ӨЧЕН ӨСТӘМӘЛӘР КҮЛӘМЕ**

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (1 төркем ) | беренче-икенче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | | 15 елдан артык | 5,5 |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (2 төркем) | беренче - өченче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 (3,0 <*>) |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 (4,5 <*>) |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 (5,5 <*>) |
| | | 15 елдан артык | 5,5 (6,5 <*>) |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (3 төркем) | беренче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | | 15 елдан артык | 5,5 |
| <*> Физкультура спорт оешмалары тренеры, инструктор-методисты (шул исәптән өлкән) | | | |

5.17. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән, стажны раслаучы документлар оешмада булса, яки стажны раслый торган кирәкле документны тапшырган көннән башкарыла.

6. Спорт резервын әзерләү оешмалары авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү күләме һәм тәртибе.

6.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тотучы билгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

биредә:

$B_{kk}$ - квалификация категориясе өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясенә өстәмә күләме, 20 нче таблицада бирелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

20 нче таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмәләр күләме**

| Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процентларда |
|---|---|
| "Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация категориясе | 5,0 |
| Югары квалификация категориясе | 8,0 |

6.2. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикалар дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикалар дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 5 нче таблицасында бирелгән.

6.3. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләү күләмен билгеләү дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләге булган хезмәткәрләргә алар булган өчен түләү хезмәткәр сайлавы буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

6.4. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә, хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәүне исәпкә алып, авыл хуҗалыгы һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

биредә:

$B_s$ - профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$- профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме, 21 нче таблицада бирелгән.

21 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 5 елга кадәр | 3,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | 15 елдан артык | 6,5 |

6.5. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән, стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, яки стажны раслый торган кирәкле документны тапшырган көннән башкарыла.

7. Спорт резервын әзерләүче оешма хезмәткәрләренә премия һәм башка кызыксындыру түләүләре төп эш урыны буенча бер үк вакытта билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен юбилей даталары белән, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле рәвештә һәм оешманың локаль актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеләнә.

7.1. Эш нәтиҗәләре буенча премия һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләме, тәртибе һәм шартлары оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләре белән билгеләнә.

7.2. Спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренә премия түләүләренә каралган хезмәткә түләү фонды күләме хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча окладны (хезмәт хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар), стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирүгә каралган хезмәткә түләү фондының кимендә 2 процентын тәшкил итә.

7.3. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләре спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 17 октябрендәге 2245 номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә спорт резервын әзерләү концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын үтәгәндә, бер тапкыр билгеләнә ала.
(7.3 пунктчасы 2020 елның 16 апрелендәге 294 номерлы ТР МК карары белән керетелгән).

8. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр спорт резервын әзерләү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренә, физик культура хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча билгеле бер вакыт өчен хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып оешма хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик зурлыкларына ирешү тора.

8.1. Спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары оешма җитәкчесе тарафыннан оешма белән идарә итүнең дәүләт-иҗтимагый характерын тәэмин итүче орган белән килештереп раслана. Спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының зурлыгы һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары оешма алдында куелган бурычлар нигезендә ел саен билгеләнә.

8.2. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләме, тәртибе һәм шартлары оешманың локаль норматив актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнә.

8.3. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kj} = \frac{FOT_k}{\sum_{i=1}^{n} \sum_{j=1}^{m} (I_{ij} \times K_i)} \times \sum_{i=1}^{n} (I_{ij} \times K_j),$$

биредә:

$B_{kj}$ - башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр;

$FOT_k$ - башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләргә каралган хезмәткә түләү фонды;

$I_{ij}$ - j хезмәткәр буенча эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең i критерие;

$K_j$ - эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының i авырлык коэффициенты;

n-эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең саны.

8.4. Эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийларын нормалаштыру төрле авырлыктагы нәтиҗәлелек критерийларының чагыштырмалылыгын тәэмин итә. Нормалаштыру эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критерие (иң яхшысы һәм начары) зурлыклары диапазонын сайлап алудан гыйбарәт, аларның берсе нормалаштырылган критерийның нуль күрсәткеченә, икенчесе берәмлеккә туры килә. Эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие зурлыгы диапазоны чикләрендә нәтиҗәлелек критериеның фактагы зурлыгын тапканда эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие нульдән алып берәмлеккә кадәр зурлыкны ала. Нәтиҗәлелек критериеның фактик зурлыгы иң начар зурлыктан түбән булганда, нормалаштырылган критерий зурлыгы - нульгә, иң яхшысыннан югарыры булганда берәмлеккә тигез итеп алына.

8.5. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие зурлыгының эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие зурлыгына бәйле булуы турыдан-туры (уңай динамика критерий зурлыгын арттыру белән билгеләнә) һәм кире (уңай динамика критерий зурлыгын киметү белән билгеләнә) булырга мөмкин.

8.6. Критерий зурлыгыннан аның зурлыгы турыдан-туры бәйле булганда, нормалаштырылган критерий түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

биредә:

$FI_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның фактагы зурлыгы;

$M_i$- эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң яхшы зурлыгы;

$L_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң начар зурлыгы.

8.7. Критерий зурлыгыннан аның зурлыгы кире бәйлелектә булганда, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = 1 - \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

биредә:

$FI_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның фактагы зурлыгы;

$M_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң яхшы зурлыгы;

$L_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң начар зурлыгы.

8.8. Авырлык коэфффициентлары булып эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның өстенлеклек дәрәҗәсе билгеләнә. Иң өстенлекле критерийга иң зур коэффициент бирелә. Чагыштырма авырлык коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_i = \frac{VK_i}{\sum_{i=1}^{n} VK_i},$$

биредә:

$K_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү i критериенең чагыштырма авырлык коэффициенты;

$VK_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү i критериенең авырлык коэффициенты.

8.9. Хезмәткәрләрнең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме 22-26 нчы таблицаларда күрсәтелгән.

22 нче таблица

**МӘГАРИФ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ЭШЧӘНЛЕК НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ КРИТЕРИЙЛАРЫ БУЕНЧА АВЫРЛЫК КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫНЫҢ ИҢ ЧИК ҖЫЕЛМА КҮЛӘМЕ**

| Тәртип N | Вазыйфаның исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 1.1. | Физик культура буенча инструктор | беренче | 45 |
| 1.2. | Педагог-оештыручы | икенче | 50 |
| 1.3. | Педагог-психолог | өченче | 55 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 2.1. | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм башка гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы структур бүлекчәләр, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешма мөдире (башлыгы) (икенче квалификация дәрәҗәсенә керетелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | беренче | 65 |
| 2.2. | Белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы аерым структур бүлекчә мөдире (башлыгы), кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе, укыту хуҗалыгы һәм башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү оешмасының (бүлекчәсенең) башка структур бүлекчәләре башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) (өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | икенче | 70 |

23 нче таблица

**Мәдәният хезмәткәрләренең эшчәнлк нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| Тәртип N | Вазыйфаның исеме | Авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Аккомпаниатор | 35 |
| 2. Әйдәп баручы звено мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Тавыш операторы | 45 |
| 2.2. | Рәссам-бизәүче | 50 |

24 нче таблица

**МЕДИЦИНА ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ЭШЧӘНЛЕК НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ КРИТЕРИЙЛАРЫ БУЕНЧА АВЫРЛЫК КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫНЫҢ ИҢ ЧИК ҖЫЕЛМА КҮЛӘМЕ**

| Тәртип N | Вазыйфаның исеме | Авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.1. | Шәфкать туташы | 40 |
| 1.2. | Массаж буенча шәфкать туташы | 40 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.3. | Фельдшер | 45 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.4. | Өлкән шәфкать туташы | 50 |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә караган табиб-белгечләрдән тыш) | 60 |

25 нче таблица

**ФИЗИК КУЛЬТУРА ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ЭШЧӘНЛЕК НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ КРИТЕРИЙЛАРЫ БУЕНЧА АВЫРЛЫК КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫНЫҢ ИҢ ЧИК ҖЫЕЛМА КҮЛӘМЕ**

| Тәр-тип N | Вазыйфаның исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Авырлык коэффициентла-рының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (1 төркем) | | | |
| 1.1. | Спорт залы буенча дежур | беренче | 5 |
| 1.2. | Беренче төркем инвалид булган инвалид-спортчыны озатып йөрүче | беренче | 5 |
| 1.3. | Спортчы | икенче | 15 |
| 1.4. | Спортчы-әйдәп баручы | икенче | 15 |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (2 төркем) | | | |
| 2.1. | Спорт буенча инструктор | беренче | 45 |
| 2.2. | Адаптив физик культура буенча инструктор | беренче | 45 |
| 2.3. | Спортчы - инструктор | беренче | 45 |
| 2.4. | Тренер - ат җайдагы | беренче | 45 |
| 2.5. | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау технигы | беренче | 45 |
| 2.6. | Күнегүләр процессы администраторы | икенче | 50 |
| 2.7 | Тренер | икенче | 50 |
| 2.8. | Адаптив физик культура буенча инструктор - методист | икенче | 50 |
| 2.9. | Адаптив физик культура һәм спорт буенча тренер - укытучы | икенче | 50 |
| 2.10. | Хореограф | икенче | 50 |
| 2.11. | Адаптив физик культура буенча өлкән инструктор - методист | өченче | 55 |
| 2.12. | Адаптив физик культура буенча өлкән тренер - укытучы | өченче | 55 |
| 2.13. | Физкультура спорт оешмасының инструктор - методисты | икенче | 50 |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (2 төркем) | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.1. | Аналитик (спорт төрләре төре яки төркеме буенча) | беренче | 60 |

26 нчы таблица

**Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары буенча авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| Тәр-тип N | Вазыйфаның исеме | Авырлык коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| "Икенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Ветеринария фельдшеры | 45 |
| 1.2. | Үсемлекләрне саклау буенча агроном (урта квалификацияле) | 45 |
| 2. "Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.1. | Агроном | 55 |
| 2.2. | Ветеринария табибы | 55 |
| 2.3. | Зоотехник | 55 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.4. | Икенче категорияле агроном | 60 |
| 2.5. | Икенче категорияле ветеринария табибы | 60 |
| 2.6. | Икенче категорияле зоотехник | 60 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.7. | Беренче категорияле агроном | 63 |
| 2.8. | Беренче категорияле ветеринария табибы | 63 |
| 2.9. | Беренче категорияле зоотехник | 63 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.10. | Әйдәп баручы агроном | 65 |
| 2.11. | Әйдәп баручы ветеринария табибы | 65 |
| 2.12. | Әйдәп баручы зоотехник | 65 |
| 3. | "Дүртенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| 3.1. | Баш агроном | 70 |

8.10. Оешманың эшчәнлек нәтиҗәлелегенең типлаштырылган критерийлары һәм аларның

оешмалар төрләре киселешендә авырлык коэффициентлары Татарстан Республикасы спорт министрлыгы тарафыннан раслана.

8.11. Спорт резервын әзерләү оешмаларында башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр фонды формалаша, аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_k = FOT_{do} \times D_k,$$

биредә:

$FOT_k$ - башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләргә каралган хезмәткә түләү фонды;

$FOT_{do}$ - төп эш урыны буенча хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) буенча спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәткә түләү фонды;

$D_k$ - башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен хезмәткә түләү фонды һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр.

Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр өчен хезмәткә түләү фондының тәкъдим ителгән күләме спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең төп эш урыны буенча вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) буенча хезмәткә түләү фондының 15 проценты күләмендә кабул ителә.

## VII. КОМПЕНСАЦИЯ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ТҮЛӘҮЛӘР

1. Спорт әзерлеге оешмаларында компенсация характерындагы түләүләргә керә:

авыл җирлегендә эшләгән өчен белгечләргә түләү;

инвалидлар һәм физик яки акыл үсешендә кимчелекләре булган затлар белән эшләгән өчен түләүләр;

зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә мәшгуль хезмәткәрләргә түләүләр;

нормаль шартлардан тайпылган шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, ике һөнәрне (вазыйфаны) бергә башкарганда, эш сәгатеннән тыш вакытта, төнлә эшләгәндә һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, локаль норматив актлар, хезмәт шартнамәсе белән билгеләнә.

3. Авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләр педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләренә, урта, әйдәп баручы звено һәм җитәкче состав хезмәткәрләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәдәният хезмәткәрләренә, икенче һәм өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче физик культура хезмәткәрләренә, урта медицина һәм фармацевтика персоналы, табиб һәм провизорларның һөнәри төркемнәренә керүче медицина хезмәткәрләренә, икенче һәм өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sm} = D_{sm} \times S,$$

биредә:

$B_{sm}$ - авыл җирендә эшләгән өчен түләүләр;

$D_{sm}$ - авыл җирендә эшләгән өчен 1 388,5 сум түләү күләме;

S - ставкаларның факттагы саны.

Белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен түләүләр шулай ук шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән түбәндәге шәһәр җирлекләрендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренә бирелә:

Апас;

Балтач;

Байлар Сабасы;

Балык Бистәсе.

4. Инвалидлар һәм физик һәм акыл үсешендә кимчелекләре булган затлар белән эшләгән өчен хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф

хезмәткәрләренә, икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче физик культура хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{ovz} = O_d \times D_{ovz},$$

биредә:

$B_{ovz}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{ovz}$ - инвалидлар һәм физик яки акыл үсешендә кимчелекләре булган затлар белән эшләгән өчен 3,5 процент өстәмә түләү күләме.

5. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә мәшгуль хезмәткәрләргә, нормаль шартлардан тайпылган шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, ике һөнәрне (вазыйфаны) бергә башкарганда, эш сәгатеннән тыш вакытта, төнлә эшләгәндә һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times D_{kh} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

биредә:

$B_{kh}$ - компенсация характерындагы түләүләр;

$O_b$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләүгә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган өстәмә күләме;

$H_{fk}$ - аның буенча законнар белән компенсация характерындагы түләүләр каралган фактта эшләнгән вакыт (ставка);

$H_n$- спорт резервын әзерләү оешмалары педагогик хезмәткәрләре хезмәт хакының база ставкасы өчен әлеге Нигезләмәнең IV бүлегендә билгеләнгән сәгать нормасы.

6. Нормаль шартлардан тайпылган шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, ике һөнәрне (вазыйфаны) бергә башкарганда, эш сәгатеннән тыш вакытта, төнлә эшләгәндә һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр төнге вакытта һәр эш сәгате өчен билгеләнә, ул нормаль шартларда эшләү белән чагыштырганда артыграк күләмдә түләнә, әмма законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән күләмнән кимрәк түгел.

Хезмәткәрне график белән аңа билгеләнгән ял көнне яки эшләми торган бәйрәм көнне эшкә җәлеп иткән очракта, хезмәт хакы алучы хезмәткәрләргә эш өчен икеләтә күләмдә түләнә, шул ук вакытта эш ял һәм эшләми торган бәйрәм көнендә эш вакытының айлык нормасы чикләрендә башкарылса, окладтан артмаган күләмдә кимендә бер көнлек яки сәгать база ставкасы күләмендә, әгәр эш айлык нормадан артып киткән булса, нигез окладыннан тыш икеләтә сәгатьлек яисә көнлек ставка күләмендә түләнә.

7. Ял яки эшләми торган бәйрәм көнендә эшләгән хезмәткәрнең теләге буенча аңа башка ял көне тәкъдим ителергә мөмкин. Бу очракта эшләми торган бәйрәм көнендә эш бер күләмдә түләнә, ә ял көненә түләү тиеш түгел.

8. Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә мәшгуль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү нормаль хезмәт шартлары белән төрле эш төрләре өчен билгеләнгән окладлар (вазыйфаи окладлар), хезмәт хакы ставкалары белән чагыштырганда арттырылган күләмдә, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә, база окладының кимендә 4 проценты күләмендә билгеләнә.

## VIII. ОЕШМА ҖИТӘКЧЕСЕ, ОЕШМА ҖИТӘКЧЕСЕ УРЫНБАСАРЫ, БАШ БУХГАЛТЕРНЫҢ ХЕЗМӘТ ХАКЫН БИЛГЕЛӘҮ ТӘРТИБЕ

1. Оешма җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларның хезмәт хакы вазыйфаи окладлардан, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән тора.

2. Спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенең вазыйфаи окладлы гамәлгә куючы тарафыннан елга бер тапкыр агымдагы елның 1 сентябренә яки оешма төзелгән көнгә, хезмәткә түләү буенча төркемнәргә карап билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

биредә:

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенең вазыйфаи оклады;

$O_b$ - җитәкченең база окладлы күләме;

S - ставкаларның факттагы саны.

Спорт резервын әзерләү оешмалары җитәкчеләренең хезмәтенә түләү буенча төркем шөгыльләнүчеләр санына бәйле рәвештә билгеләнә.

3. Спорт резервын әзерләү оешмалары җитәкчеләре урынбасарлары һәм баш бухгалтерларының вазыйфаи окладлары әлеге оешма җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

4. Җитәкчеләр хезмәтенә түләү төркеме, җитәкчеләрнең база һәм вазыйфаи окладлары күләме 27 таблицада бирелгән.

5. Спорт резервын әзерләү оешмасын гамәлгә куючы спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенә, башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен, эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгеләргә мөмкин.

Спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләр 27 нче таблицада бирелгән.

Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенә ай саен, бер ел эчендә башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесе спорт резервын әзерләү оешмаларының җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен, аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, стимуллаштыру характерындагы түләүне билгели ала. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, бер ел эчендә башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесе башкарган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты күләмендә билгеләнә.

27 нче таблица

## СПОРТ РЕЗЕРВЫН ӘЗЕРЛӘҮ ОЕШМАЛАРЫ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕНЕҢ БАЗА ОКЛАДЛАРЫ ҺӘМ БАШКАРЫЛГАН ЭШЛӘРНЕҢ СЫЙФАТЫ ӨЧЕН СТИМУЛЛАШТЫРУ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ТҮЛӘҮЛӘР КҮЛӘМЕ

| Җитәкче хезмәтенә түләү буенча төркем | Күләмле күрсәткечнең зурлыгы (дәүләт биреме нигезендә агымдагы елның 1 сентябренә шөгыльләнүчеләр саны), кеше <*> | База оклады, сумнарда | Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | 0 - 200 | 18 000 | 1 000 |
| 2 | 201 - 400 | 20 000 | 2 000 |
| 3 | 401 - 700 | 24 000 | 2 000 |
| 4 | 701 - 1 200 | 25 000 | 3 000 |
| 5 | 1 201 - 1 800 | 28 000 | 4 000 |
| 6 | 1 801 һәм югарырак | 30 000 | 5 000 |

| |
|---|
| <*> Спорт резервын әзерләү оештмасының укучылар контингенты (спорт-адаптив мәктәп) 3 коэффициенты белән исәпкә алына |

7.Спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчеләре, җитәкче урынбасарлары, баш бухгалтерлары эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең типлаштырылган критерийлары һәм аларның авырлык коэффициентлары карамагында спорт резервын әзерләү оешмалары булган Татарстан Республикасының тармак министрлыклары тарафыннан раслана.

Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_c \times K_{VK},$$

биредә:

